**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Зәй-Каратай авыл җирлеге**
**Үзбәк авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2020 елның 20 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлегенең Үзбәк авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Зәй-Каратай авыл җирлеге Үзбәк авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм хәрби хәрәкәттә катнашучылар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм хәрби хәрәкәттә катнашучыларның тол калган хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

1) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

- Үзәк авылы зираты территориясен төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Зәй - Каратай авылы, Совет урамы, 99 йорт, 1 корылма, Үзбәк авылы, Луговая урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Зәй-Каратай авыл җирлеге башлыгы М.И. Идиятова